Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен административ регламент раслау турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы (13.07.2015 ред.) нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан 1-49 нчы кушымталар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын расларга.

2. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карарының үз көчен югалтуын тану турында:

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 5 апрелендәге 277 номерлы карары;

2015 елның 12 февралендәге 70 номерлы «Чүпрәле муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында»гы карары;

2016 елның 25 гыйнварындагы 28 номерлы «Чүпрәле муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында»гы карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов